**Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Иске Барыш авыл җирлеге Советы карары**

**2017 елның 25 сентябре №47**

**Җирле референдум уздыру инициативасы турында**

“Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында” 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясы, “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 22, 56 статьялары, “Җирле референдум турында” 2004 елның 24 мартындагы 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 17 статьясы, Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Иске Барыш авыл җирлеге Уставының 15 статьясы, Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Иске Барыш авыл җирлеге Советы КАРАР ЧЫГАРДЫ:

1. Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Иске Барыш авыл җирлеге территориясендә җирле референдум уздыруны түбәндәге мәсьәлә буенча хәл итәргә:

«2017 елда үзара салым кертүгә Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Иске Барыш авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, көндезге формада белем алучы студентлардан тыш, 500 сум күләмендә һәм түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны җибәрү белән килешәсезме:

*** - җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге:**

- вак ташлы өслекле юлны ремонтлау: Иске Барыш авылы, Мәктәп ур., у. Елга урамы; Картапа авылы, Родниковая ур., Мирная ур., Яшьләр ур., Мәктәп ур.

“Әйе Юк"

2. Әлеге карарны түбәндәге адреслар буенча урнашкан мәгълүмат стендларында игълан итәргә:

- Татарстан Республикасы, Кама Тамагы муниципаль районы , Иске Барыш авылы, Үзәк ур.

шулай ук Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Татарстан Республикасы Кама Тамагы районының Иске Барыш авыл җирлеге башлыгы ,

Совет рәисе И.Р.Зиганшин